МИНИСТЕРСТВО
ЛЕСНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
УРМАН ХУҖАЛЫГЫ
МИНИСТРЛЫГЫ

---

ПРИКАЗ БОЕРЫК

09.10.2019 г.Казань № 1068-осн

Татарстан Республикасы
Урман хуҗалыгы
министрлыгы эмблемасын
гамәлгә кую турында

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Геральдика советы турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы ПУ-21 номерлы Указы нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы рәсми символларыннан файдалануны системалаштыру максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы эмблемасын гамәлгә куярга.

2. Кушымтада бирелгәннәрне расларга:

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы эмблемасы турында нигезләмә;

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы эмблемасының тасвирламасы;

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы эмблемасының рәсеме.

3. Юридик бүлеккә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрергә.

4. Дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре секторына, мәгълүмат технологияләрен үстерү секторы белән берлектә, әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының структур бүлекчәләре һәм ведомство буйсынуындагы дәүләт казна һәм бюджет учреждениеләре җитәкчеләренә җиткерергә.

5. Әлеге Боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр Р.Ә. Кузюров

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2019 елның 09.10. № 1068-осн боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы эмблемасы турында нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Эмблема – оешманың төп идеясен гәүдәләндерүгә юнәлдерелгән шартлы яки символик сурәт. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы эмблемасы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2007 елның 12 февралендәге 38 номерлы карары нигезендә эш итүче башкарма хакимият органы – Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының рәсми символы булып тора.

1.2. Эмблема Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан функцияләрне нәтиҗәле тормышка ашыру һәм сыйфатлы дәүләт хезмәтләре күрсәтү символы булып тора.

1.3. Эмблема Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Геральдика советы тарафыннан каралырга һәм Татарстан Республикасы Геральдика реестрына кертелергә тиеш.

1.4. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының эмблемага хокукы Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә саклана.

## 2. Куллану өлкәсе

2.1. Эмблема Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгын индивидуальләштерү өчен файдаланыла һәм түбәндәгеләрдә кулланылырга мөмкин:

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының ведомство бүләкләрендә;

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының рәсми интернет-сайтында;

мәгълүмати басма матбугатларда, кино-видео һәм фотоматериалларда; экспозицияләрдә һәм семинарларның, киңәшмәләрнең презентация материалында; Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан эшләнелүче программаларда;

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы ярышларында катнашучыларның спорт формасында.

2.2. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы эмблемасын куллануның башка очраклары Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министры тарафыннан билгеләнә.

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2019 елның 09.10. № 1068-осн боерыгы белән расланды

## Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы эмблемасының тасвирламасы

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының эмблемасы әйләнәдән гыйбарәт. Әйләнәдә шартлы рәвештә ылыслы һәм яфраклы агачлар сурәтләнгән: үзәк өлешендә – чыршы, аннан сул якта – башка чыршы агачының бер өлеше, уңда – каен; барлык сурәтләр дә яшел төстә. Аскы ягының уң өлешендә, әйләнә чигеннән чыгарып, шартлы сурәтләрдән композиция урнаштырылган: нарат күркәсе һәм ике имән чикләвеге – алтын төсендә; имән яфрагы һәм нарат ботагы – яшел төстә.

Әйләнә киңлекләре Татарстан Республикасының Дәүләт флагындагы тиешле полосаларның киңлегенә пропорциональ булган яшел, ак һәм кызыл төстәге полосалар белән әйләндереп алынган. Полосалар буйлап кара төс белән "Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы" дигән язу урнаштырылган. Полосалар белән язу шартлы сурәтләрдән композиция урнаштырылган урында аерыла.

Татарстан Республикасы Урман
хуҗалыгы министрлыгының
2019 елның 09.10. № 1068-осн
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы
эмблемасының рәсеме